# СИҢА КИЛДЕМ, ИРКӘМ

*РИМ ХАСАНОВ көе*
*ГЫЙЛЬМАН ИДРИСОВ сүзләре*

Сиңа килдем, иркәм,
Үткән юлларымның
Саный-саный ерак чакрымнарын.
Килдем тормышымда кичеп
язмышымның
Шатлыкларын, көчле ялкыннарын.

Сиңа килдем, иркәм,
Килдем еллар буе,
Саный-саный үткән көннәремне.
Баса алмаенча ярсып януларын
Әрнеп өзгәләнгән йөрәгемнең.

Сиңа килдем, иркәм,
Бик сагынып килдем,
Шаулап-гөрләп ямьле язлар җиткәч.
Ераклардан язган сәлам хатларыңны
Көтә-көтә түземлегем беткәч.